ГОСУДАРСТВЕННАЯ ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Б.Красная, 15/9, г.Казань, 420111

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ
Зур Кызыл ур. 15/9, Казан шәһәре, 420111

тел/факс. 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

№ 322

**П Р И К А З** **Б О Е Р Ы К**

«23» август, 2018ел.

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза турында

«Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 24 декабрендәге 883 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына, шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә эшләнә торган норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибен (кушымтада бирелә) расларга.
2. Юридик бүлек башлыгына (Н.Н. Воронская) әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.
3. Әлеге боерык үтәлешен тикшерүдә тотуны башлык урынбасары – хокук идарәсе башлыгы В.С. Саттаровка йөкләргә.

Башлык С.А. Крайнов

Килештерелде:
ТР ДТИ башлыгы урынбасары – хокук идарәсе башлыгы В.С.Саттаров

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2018 елның «___» __________ № __________ боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру тәртибе

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе (алга таба – ТР ДТИ) норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына (алга таба – актлар, актларның проектлары), шулай ук ТР ДТИ эшләнә торган Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларына (алга таба – эшләнә торган акт проекты) коррупциягә каршы экспертиза уздыру процедурасын билгели.

1.2. Коррупциягә каршы экспертиза коррупциягә каршы көрәш турында законнар, «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 24 декабрендәге 883 номерлы карары нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана торган норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру методикасы (алга таба – методика) нигезендә уздырыла.

1.3. Коррупциягә каршы экспертизага килгән актлар (актларның проектлары, эшләнә торган актларның проектлары) коррупциягә каршы экспертизага килгән норматив хокукый актларны һәм норматив хокукый актларның проектларын исәпкә алу журналында (алга таба – Журнал) (әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасы) теркәлә.

1.4. Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре буенча әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтага туры китерелгән формада бәяләмә төзелә, анда түбәндәге белешмәләр чагылдырыла:

экспертизага тапшырылган актның реквизитлары (акт проектының, эшләнә торган акт проектының аталышы);

экспертиза уздыру нигезе;

актта (акт проектында, эшләнә торган акт проектында) коррупциячел факторларның булуы яки юклыгы;

актның (акт проектының, эшләнә торган акт проектының) коррупциячел факторларны үз эченә алган конкрет нигезләмәләре;

хокукый нормаларның тәгъбирләнешләрен үзгәртү яки коррупциячеллекне бетерү өчен аерым нормаларны төшереп калдыру буенча тәкъдимнәр.

## 2. ТР ДТИ актларына коррупциягә каршы экспертиза

2.1. ТР ДТИ актларына коррупциягә каршы экспертиза ТР ДТИ хокук идарәсенең юридик бүлеге башлыгы тарафыннан яки бүлек башлыгы вазыйфаларын башкаручы бүлек хезмәткәре (алга таба – җаваплы зат) тарафыннан уздырыла.

2.2. ТР ДТИ актларына коррупциягә каршы экспертиза әлеге актны чыгару инициаторы булган структур бүлекчә тарафыннан актларның кулланылуына мониторинг уздырылганда аларда коррупциячел факторлар ачыкланганда, шулай ук теләсә нинди ысул белән актларда коррупциячел факторлар булуы турында мәгълүмат алынганда җаваплы зат яки ТР ДТИ башка хезмәткәрләре тарафыннан уздырыла. Актлар шулай ук ТР ДТИ җитәкчелеге тарафыннан да экспертиза уздыру өчен җибәрелергә мөмкин.

Коррупциягә каршы экспертиза көчен югалткан яки гамәлдән чыгарылган норматив хокукый актларга карата үткәрелми.

2.3. Актлар җаваплы зат тарафыннан Журналда коррупциячел факторлар ачыкланган, тиешле мәгълүмат алынган яки ТР ДТИ җитәкчелеге тарафыннан акт җибәрелгән көнне теркәлә.

2.4. Коррупциягә каршы экспертиза актны Журналда теркәгән көннән соң ункөнлек чорда уздырыла.

Актка коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре әлеге Тәртипнең 1.4 пункты нигезендә җаваплы зат тарафыннан төзелә торган бәяләмә белән рәсмиләштерелә һәм Журналда чагылдырыла.

2.5. Бәяләмә төзелгән һәм имзаланган көннән башлап бер эш көне узганчы җаваплы зат тарафыннан ТР ДТИ башлыгының тикшереп торучы урынбасарына – ТР ДТИ хокук идарәсе башлыгына яки аның вазыйфаларын башкаручы затка җибәрелә. ТР ДТИ башлыгының тикшереп торучы урынбасары – хокук идарәсе башлыгы (аның вазыйфаларын башкаручы зат) бәяләмәгә кул куя һәм ТР ДТИ башлыгына яки аның вазыйфаларын башкаручы затка (алга таба – ТР ДТИ башлыгы) тапшыра.

2.6. ТР ДТИ башлыгы актта коррупциячел факторлар булуы турында бәяләмә нәтиҗәләре буенча аңа үзгәрешләр кертү зарурлыгы турында яки аны көчен югалткан дип тану турында карар кабул итә.

2.7. Әлеге актны чыгару инициаторы булган структур бүлекчә ТР ДТИ башлыгы тарафыннан әлеге Тәртипнең 2.6 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң өч көнлек срокта тиешле ТР ДТИ акты проектын әзерли һәм аны коррупциягә каршы экспертизага җаваплы затка җибәрә. Мондый проектка коррупциягә каршы экспертиза әлеге Тәртипнең 3 нче бүлегенә туры китереп уздырыла.

## 3. ТР ДТИ актлары проектларына, шулай ук ТР ДТИ эшләнә торган Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза

3.1. ТР ДТИ актлары проектларына, шулай ук эшләнә торган актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза бер үк вакытта аларга хокук

экспертиза уздырып гамәлгә ашырыла.

3.2. ТР ДТИ актлары проектлары һәм эшләнә торган актларның проектлары коррупциягә каршы экспертиза уздыру өчен тиешенчә проектны эшләү өчен җаваплы булган ТР ДТИ структур бүлекчәсе җитәкчесе тарафыннан җаваплы затка (ТР ДТИ хокук идарәсенең юридик бүлеге башлыгына) җибәрелә.

3.2. Килгән ТР ДТИ актлары проектлары һәм эшләнә торган актларның проектлары (алга таба – проектлар) җаваплы зат тарафыннан килгән көнендә Журналда теркәлә. Коррупциягә каршы экспертиза проект теркәлгән көннән соң ункөнлек чорда уздырыла.

3.3. Актка коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре әлеге Тәртипнең 1.4 пункты нигезендә җаваплы зат тарафыннан төзелә торган бәяләмә белән рәсмиләштерелә һәм Журналда чагылдырыла. Бәяләмә төзелгән көнендә проектны җибәргән структур бүлекчәгә тапшырыла.

3.4. Коррупциячел факторлар булганда проектны әзерләгән структур бүлекчә бәяләмә алынган көннән башлап өч көнлек срокта проектны өстәмә эшләп бетерә һәм аны яңадан коррупциягә каршы экспертиза уздыру өчен җаваплы затка җибәрә. Кабат уздырыла торган коррупциягә каршы экспертиза өстәмә эшләп бетерелгән проектны алган көннән соң өч көнлек чорда уздырыла.

3.6. Өстәмә эшләп бетерелгән проектта коррупциячел факторлар булмаган очракта, җаваплы зат тиешле бәяләмәне проектны яңадан коррупциягә каршы экспертизага юллаган структур бүлекчәгә җибәрә.

## 4. ТР ДТИ актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза

4.1. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза объектлары булып «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә ТР ДТИнең gji.tatarstan.ru рәсми сайтында (алга таба – сайт) урнаштырылган ТР ДТИ норматив хокукый актлары проектлары (алга таба – актларның проектлары) тора.

4.2. Актларның проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру өчен ТР ДТИнең күрсәтелгән проектларны эшләү өчен җаваплы структур бүлекчәсе аларны карау өчен ТР ДТИ хокук идарәсенең юридик бүлегенә җибәрә.

4.3. Актларның проектларын коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру өчен җибәрүгә җаваплы булган вазыйфаи зат акт проектын алган көннән соң бер эш көне эчендә аны Мәгълүмат ресурсында урнаштыру өчен җыелма анализ һәм автоматлаштыру бүлегенә җибәрә.

4.4. Җаваплы зат актларның проектлары коррупциягә каршы бәйсез экспертизага җибәрелгән көнгә туры килә торган бер эш көне эчендә аталган проектларны, тәкъдимнәрне һәм кисәтүләрне җибәрү өчен адресын (шул исәптән проектны эшләү өчен җаваплы затның электрон почта адресын), шулай ук коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыра башлауның һәм тәмамлауның биш эш көненнән азрак була алмаган даталарын күрсәтеп, Мәгълүмат ресурсында урнаштыра.

4.5. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру нәтиҗәләре буенча бәяләмәләр килгән көннән соңгы эш көненнән соңга калмыйча ведомствоара электрон документ әйләнешенең бердәм системасында теркәлә һәм акт проектын әзерләү өчен җаваплы булган ТР ДТИ структур бүлекчәсенә җибәрелә.

4.6. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмә киңәш

итү холкына ия һәм ТР ДТИ килгән көненнән башлап 30 көнлек чорда зарури каралырга тиеш. Карау нәтиҗәләре буенча бәйсез экспертизаны уздырган юридик яки физик затка нигезләнгән җавап җибәрелә, бәяләмәдә ачыкланган коррупциячел факторларны бетерү ысулы турында тәкъдимнәр булмаган очраклардан тыш.

4.7. Акт проектына коррупциягә каршы бәйсез экспертизаны зудырганда ачыкланган коррупциячел факторлар акт проектын өстәмә эшләү стадиясендә аны әзерләүче тарафыннан бетерелә.

4.8. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза бәяләмәсендә бәян ителгән кисәтүләрне юкка чыгаргач һәм тәкъдимнәрне исәпкә алганнан соң, ТР ДТИнең акт проектын әзерләү буенча җаваплы булган структур бүлекчәсе акт проектын, коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча килгән бәяләмәләрне теркәп, яңадан карап тикшерү өчен ТР ДТИ хокук идарәсенең юридик бүлегенә тапшыра. Кабат карау өч көнлек чорда гамәлгә ашырыла.

4.9. ТР ДТИ актлары проектларында коррупциячел факторлар булуы турында таныклый торган коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре белән ТР ДТИ ризалашмаган очракта, ТР ДТИ, законнарда билгеләнгән тәртиптә, аталган актларның проектларын, коррупциягә каршы бәйсез экспертиза бәяләмәсен һәм үзенең ризасызлыгын нигезләгән аңлатма язуын теркәп, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына коррупциягә каршы экспертизага җибәрә.

4.10. Документны эшләүче зат ТР ДТИдә эшләнгән, Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасына закон чыгару инициативасы тәртибендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан кертелә торган федераль законнар проектларында, Татарстан Республикасы законнары проектларында, Татарстан Республикасы Президенты указлары проектларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары проектларында коррупциячел факторлар булуы турында таныклый торган коррупциягә каршы, шул исәптән бәйсез, экспертиза нәтиҗәләре белән ризалашмаган очракта, документны эшләүче зат аталган норматив хокукый актларның проектларын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына карау өчен кертә.

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру тәртибенә 1 нче кушымта

Коррупциягә каршы экспертизага килгән норматив хокукый актларны һәм норматив хокукый актларның проектларын исәпкә алу журналы

| Актның (акт проектының) экспертизага килү датасы | Актны (акт проектын) тапшырган структур бүлекчә | Актның (акт проектының) аталышы | Коррупциячел нормаларның булуы/юклыгы | Бәяләмәне төзү датасы | Искәрмәләр (яңадан уздырылган экспертиза турында мәгълүмат, яңадан уздырылган экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмә төзелү датасы) (актларның проектларына карата) |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру тәртибенә 2 нче кушымта

Коррупциягә каршы экспертиза
бәяләмәсе

______________________________________________________________________________
(норматив хокукый актның реквизитлары яки норматив хокукый акт проектының аталышы)

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________
(килгән датасы)

______________________________________________________________________________
(экспертиза уздыру датасы)

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 24 декабрендәге 883 номерлы карары

(коррупциягә каршы экспертиза уздыру нигезе)

Проектта коррупциячел нормаларның булуы яки юклыгы:

__________________________________________________________________________

Акт проектының коррупциячел нормаларны үз эченә алган конкрет нигезләмәләре:

__________________________________________________________________________

Тәгъбирләнешләрне үзгәртү яки коррупциячеллекне бетерү өчен аерым нормаларны төшереп калдыру буенча тәкъдимнәр:

______________________________________________________________________________

_____________________________________________________________________________

Җаваплы зат ________________ ________________________________
(имза) (Ф.И.А.)